**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агачлар һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); (Түбән Көек авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));

2. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Түбән Көек авылы зиратын төзекләндерү: зиратка койма кору өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, (Түбән Көек авылының урам юлларын грейдлау кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.

Совет Түбән Көек сельского поселения
Түбән Көек авыл җирлеге советы
ИНН 1610000518